КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 декабрь г.Казань № 1623

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 май, 385 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1356 нчы; 2022 ел, 25 апрель, 393 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1468 нче; 2023 ел, 14 февраль, 143 нче; 2023 ел, 16 март, 260 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

беренче абзацта «2023 елда» сүзләрен «2023 – 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «2023 елда» сүзләрен «2023 – 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «2023 елда» сүзләрен «2023 – 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2023 елда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турындагы нигезләмәдә:

исемендә «2023 елда» сүзләрен «2023 – 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

1.1 пунктта «2023 елда» сүзләрен «2023 – 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

8.1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) карауга мохтаҗ граждан (аның законлы вәкиле) мөрәҗәгать иткән көнне, озак вакыт карау системасында катнашучыдан мәгълүмат кергән көнне карауга мохтаҗ граждан турында алынган мәгълүматны гражданның яшәү урыны буенча аның янына бергәләп баруны оештыру өчен координация үзәгенә һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә тапшыра.

Граждан янына бергәләп бару кысаларында:

халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге белгече гражданның тормыш эшчәнлеге шартларын тикшерә;

координация үзәгенең белгече – карауга мохтаҗ булуны бәяләү буенча эксперты:

гражданның социаль хезмәт күрсәтүгә, шул исәптән карау буенча социаль хезмәт күрсәтүләргә индивидуаль ихтыяҗын билгели һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган тәртиптә карауга мохтаҗ булу дәрәҗәсен билгели. Гражданның социаль хезмәт күрсәтүгә, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтүләргә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү нәтиҗәләре буенча, озак вакыт карау системасы кысаларында аның карауга мохтаҗ булу параметрларыннан чыгып, карауга мохтаҗ булу дәрәҗәсе билгеләнә: карауга мохтаҗ булуның беренче дәрәҗәсе – үз-үзенә хезмәт күрсәтү һәм хәрәкәтләнү сәләте нык (сизелерлек) кимү аркасында карауга уртача дәрәҗәдә мохтаҗ булу; карауга мохтаҗ булуның икенче дәрәҗәсе – үз-үзенә хезмәт күрсәтү һәм хәрәкәтләнү сәләте аеруча нык кимү аркасында карауга шактый мохтаҗ булу; карауга мохтаҗ булуның өченче дәрәҗәсе – үз-үзенә хезмәт күрсәтү сәләте тоталь дәрәҗәдә бетү аркасында карауга тулусынча бәйле булу;

социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында хәбәр итә. Гражданның социаль хезмәтләр алуга ризалыгы булмаган очракта, аңа социаль хезмәтләр күрсәтүдән язма рәвештә баш тартырга тәкъдим итә. Граждан белән бергә яшәүче һәм аны мөстәкыйль карауны планлаштыручы туганнары булганда, аларга «Тәрбия мәктәбе» стационар биләү технологияләре кысаларында карау күнекмәләрен өйрәнергә тәкъдим итә;

гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту) турында карар проектын әзерли, социаль хезмәт күрсәтү формасын сайлый, озак вакыт карау буенча социаль пакетка кертелә торган карау буенча социаль хезмәт күрсәтүләрне һәм башка социаль хезмәт күрсәтүләрне сайлый, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы проектын һәм аңа кертелә торган өстәмәләрне әзерли;»;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның нумерация башисемендә «2023 елда» сүзләрен «2023 – 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтаның нумерация башисемендә «2023 елда» сүзләрен «2023 – 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2023 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чараларны финанс белән тәэмин итү кагыйдәләре исемендә «2023 елда» сүзләрен «2023 – 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2023 елда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының карауга мохтаҗ гражданнарга өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтүче «карау буенча ярдәмче» һөнәре буенча хезмәткәрләренең хезмәт хакын билгеләү үзенчәлекләре турындагы нигезләмәдә:

исемендә «2023 елда» сүзләрен «2023 – 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «2023 елда» сүзләрен «2023 – 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин